20. Арча муниципаль районы башкарма комитеты һәр хезмәткәр өчен билгеләнгән индивидуаль, һәм (яисә) берничә хезмәткәр өчен билгеләнгән коллектив нормаларны, күрсәтелгән органнарның структур бүлекчәләре буенча товарлар, эшләр, хезмәтләр санының һәм (яисә) бәяләренең нормативларын эшли һәм раслый.

21. Арча муниципаль районы башкарма комитетының норматив чыгымнарны раслый торган хокукый актларын түбәндәгеләр билгеләргә тиеш:

а) норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләре белән исәпләү тәртибе билгеләнмәгән норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе;

б) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр саны һәм (яисә) бәяләре, шул исәптән хезмәткәрләр вазыйфалары һәм (яисә) хезмәткәрләр вазыйфалары категорияләре буенча төркемләнгән нормативлар.

22. Әлеге документның 1 пунктының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән хокукый актлар бер яисә берничә заказчы сатып ала торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә һәм (яисә) Арча муниципаль районы башкарма комитеты функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнар билгели ала.

23. Товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә һәм норматив чыгымнар тиешле заказчы сатып алу объектын һәм (яисә) объектларын нигезләү өчен кулланыла.